КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 30 июнь г.Казань № 521

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2020 ел йомгаклары буенча башкарма дисциплинаның, халыкның тормыш сыйфатын һәм аларның эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү индикаторлары буенча Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарына идарә итүгә дәүләт йөкләмәсен Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан үтәүнең торышы турында» 2021 ел, 23 апрель, 278 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2020 ел йомгаклары буенча башкарма дисциплинаның, халыкның тормыш сыйфатын һәм аларның эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү индикаторлары буенча Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарына идарә итүгә дәүләт йөкләмәсен Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан үтәүнең торышы турында» 2021 ел, 23 апрель, 278 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. 2021 елның 1 июленә кадәр:

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына Татарстан Республикасы Бюджет кодексын гамәлгә ашыру максатларында норматив хокукый актлар проектларын эшләргә һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертергә;

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2009 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы

Татарстан Республикасы законын гамәлгә ашыру максатларында норматив хокукый акт проектын эшләргә һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертергә.

2021 елның 1 октябренә кадәр Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына «Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында» 1998 елның 25 ноябрендәге 1872 номерлы Татарстан Республикасы законын гамәлгә ашыру максатларында норматив хокукый акт проектын эшләргә һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертергә.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин